# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге составына керүче Коры Көрнәле авылы

16 декабрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге составына керүче Коры Көрнәле торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2022 елда Көрнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

-кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- торак пунктта урамнарны яктырту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- торак пункттагы юлларны төзекләндерү (юлларга вак таш җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу (төзелеш материалы сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- су башнясы өчен су насослары алу;

2. Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Көрнәле авыл җирлеге башлыгы Д.Б.Казакова